**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЙДАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**дүртенче чакырылыш утыз өченче утырыш**

**Айдар авылы** **№ 97** **25.03.2024 ел.**

Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге Советының 2015 елның 16нчы июне 172 номерлы « Айдар авыл җирлеге муниципаль милкендә булган, аларга карата дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм куллану тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 628-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге Советының 2015 елның 16нчы июне 172 номерлы «Айдар авыл җирлеге муниципаль милкендә булган, аларга карата дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм куллану тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карарына (15.11. 2021 № 30 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган Айдар авыл җирлеге муниципаль милкендә булган, аларга карата дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм куллану тәртибе турында нигезләмәнең 6.1 пунктындагы «, адреслы инвестицион программалар белән» сүзләрен «һәм (яисә) региональ инвестиция программалары белән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә халыкка җиткерергә.

Айдар авыл җирлеге башлыгы Х.Ш.Хәсәншин